*/Безнең бәйрәмнәр/*

### Корбан гаете – сахрада



Җәйге каникулда укучыларның ялын файдалы һәм кызыклы үткәрү, туган халкының бәйрәмнәренә, гореф-гадәт, йолаларыга игътибарлы итү максатыннан Югары кырдагы кала урынында балалар өчен Корбан ашы уздырылды. Мәктәп директоры Насыйров Рафик Гомәр улы үз хуҗалыгыннан чалган корбан итеннән укучылар өчен шашлык һәм шулпа әзерләтте. Казанда аш пешкәнче, укучылар хәрәкәтле уеннар уйнап, табигатьне күзәтеп рухи азык алдылар. Табигатьтә таң каршылау өчен сигез укучыбыз шушы бәйрәм хөрмәтенә мәчеттән мәктәпкә бүләк итеп бирелгән палаткаларда куна калдылар. Чарада җәйге каникулга авылга кайткан балалар да, югары уку йортында белем алучы студентлар да катнашты.

***Әминә Туктамышева, Х сыйныф укучысы***

*/Безнең спорт/*

### Җәйге бәйгеләр



Җәйге чорның төп бәйгесе Сабан туе мәйданнарында уза дисәк тә ялгышмабыз. Алдагы еллардагы кебек үк быел да көрәшче егетләребез берничә бәйрәмдәге көрәштә катнашып, җиңүләр яулап кайттылар.

Чистай шәһәре һәм районы Сабан туе көрәшендә үз авырлыкларында Камалов Илдус белән Хәбибрахманов Ильяс беренче, ә Нурматов Халит икенче урыннарны яуладылар. Ильяс белән Илдус киң форматлы телевизорлар, Халит – кыйммәтле телефон белән бүләкләнделәр.




Хәбибрахманов Ильяс өчен быелгы Сабан туйлары аеруча зур уңыш китерде. Аның җиңүләре май ахырында авылыбызда уздырылган балалар Сабан туенда батыр калудан башланып китте. Аксубай Сабан туенда Ильяс, барлык көндәшләрне дә җиңеп, яшьләр арасында районның абсолют батыры дәрәҗәсен алуга иреште. Район Сабан туенда безнең мәктәп көрәшчеләреннән Халит – икенче, Илдус – өченче урыннарны алуга ирештеләр.

Билгеле булганча, чуаш халкының "Уяв" бәйрәмнәре дә көрәшсез узмый. 3 нче июль көнне Норлат шәһәрендә узган "Уявта" Камалов Илдус белән Хәбибрахманов Ильяс беренче, Гогиев Аслан – икенче урыннарны алдылар.

*/Котлыйбыз!/*




Ямьле җәй айларында күп кенә мәктәп балалары һәм хезмәткәрләренең туган көннәре булып узды.

Гафиятуллин Фаил (24 нче июнь), Хөснуллин Марат (24 нче июнь), Җамалетдинов Фирдүс (2 нче июль), Нурматов Муса (6 нчы июль), Сафиуллина Гөлсем (9 нчы июль), Җамалетдинов Зөлфәт (23 нче июль), Нурматова Зәйнәп (29 нчы июль), Залиев Салават (6 нчы август), Насыйрова Кәүсәр (18 нче август).

Шакиров Азат абый (16 июнь), Насыйрова Гөлүсә апа (24 нче июнь), Гафиятуллина Руфия апа (26 нчы июнь), Сафиуллина Алсу апа (16 нчы июль), Сабитова Илсөяр апа (8 нче август).

Кадерле дуслар, апалар һәм абыйлар! Сезне барыгызны да дөньяга килгән көннәрегез белән тәбрик итәбез! Ныклы сәламәтлек, тыныч һәм мул тормыш, укуыгызда һәм эшегездә зур уңышларга ирешүегезне, хыялларыгызның чынга ашуын телибез!

Газетаны гамәлгә куючы – Түбән Майна урта мәктәбе
Мөхәррир – Фәнүзә Гафиятуллина
Редколлегия әгъзалары:
Әминә Туктамышева, Сара Насыйрова
Виктория Нукина, Рузилә Мөхәммәтова
Зөлфирә Сафиуллина



# Мәктәп хәбәрчесе

**№6 (№27) июнь-август 2021 ел**

**Түбән Майна урта мәктәбе газете**

Тел. 8 (84344) 4-38-46 sch1644maina@mail.ru



*/Мөхәррир сүзе/*

### Балалар иминлеге – уртак бурычыбыз

Хөрмәтле әти-әниләр! Барыбыз өчен дә иң кадерле һәм кыйммәтле зат – балаларыбыз. Безнең, өлкәннәрнең бурычы – баланы саклау һәм яклау, аны төрле катлаулы, кайвакыт куркыныч тормыш ситуацияләре белән очрашуга дөрес итеп әзерләү. Балалар куркынычсызлыгы темасы һәр көнне һәм сәгатьтә актуаль. Мәктәпкәчә яшьтәге чорда да, өлкән сыйныфларда да бала бик күп кагыйдәләр, нормалар, кисәтүләр, таләпләр белән таныша. Еш кына төрле сәбәпләр аркасында аларны үтәү аз нәтиҗәле булып чыга. Балалар үсешенең төп эчтәлеген һәм юнәлешен билгеләп, без сезнең белән, балалар тайпылышсыз үтәргә тиешле тәртип кагыйдәләрен билгеләргә тиеш. Чөнки моңа аларның сәламәтлеге һәм иминлеге бәйле.

Җәй көне озын елларда балаларыбызның сәламәтлеген кайгырту, юл-транспорт травматизмыныннан саклау да ата-аналар һәм укытучылар өстенә йөкләтелгән. Статистика күрсәткәнчә, балалар катнашындагы юл һәлакәтләре каникуллар чорында аеруча еш кабатлана. Чөнки балалар буш вакытларын урамда, гадәттә, өлкәннәр күзәтчелегеннән башка үткәрәләр.

Җәйге чорда ике көпчәкле транспорт чаралары катнашында аварияләр саны арта. Беренче чиратта, балигъ булмаган велосипедчылар, скутерчылар юл–транспорт фаҗигасенә сәбәпче булалар. Безнең авылда да берничә мопед исәпләнә. Алар белән төүлекнең караңгы вакытында йөрү – бу күңелсезлекләрне тагын да арттыруы мөмкин. Шуңа күрә балаларыбызның сәламәтлеген кайгыртып, ялгыш адымнардан тыйсак иде. 14 яшькә кадәр балигъ булмаганнар тарафыннан кылынган хокук бозулар өчен укучыларның ата-аналары административ җаваплылык тота. Алар 23.00 сәгатькә кадәр йөри алалар. 23.00 сәгатьтән 6.00 сәгатькә кадәр ата-аналар озатып йөрүе мәҗбүри. Гомумән алганда, әти-әниләр балаларының өйдән чыгып киткәч кайда йөрегәнен белеп торырга тиеш. Күңелсез хәлләрне булдырмау, балаларыбызның якты күләчәген уйланмый эшләнгән начар эшләр белән буямас өчен, ныграк контрольдә тотсак иде.

Бала иминлегенең тагын бер төп шартларының берсе – ул сезгә ышаныч. Ни генә булмасын, ул белергә тиеш: әти һәм әни һәрвакыт ярдәм итәр. Кыскасы, балаларның иминлеге – һәрвакыт диярлек аларның әти-әниләре эше. Балаларыбызга игътибарлы булыйк, аның ышанычына лаек булыгыз – бәхетсезлек очракларының күбесен кисәтеп булачак.

***Мөхәррир Фәнүзә Гафиятуллина***

### Бәйрәм белән!

**30 нчы август - Татарстан Республикасы бәйсезлеге көне**




**Күп гасырлар кичкән чал тарихлы,**
**Данлы илем, үзең бер дастан!**
**Синдә генә безнең язмышыбыз**
**Республикам минем — Татарстан!**



*/Рәсми хәбәрләр/*

### 2020-2021 уку елы нәтиҗәләре

Узган 2020-2021 нче уку елын мәктәпнең 54 укучысы тәмамлады. Уку елы нәтиҗәләре буенча белем сыйфаты 41% тәшкил итте. Кызганычка каршы, бу күрсәткеч күтелгәннән күпкә түбәнрәк булды.

Чыгарылыш сыйныфларыннан XI сыйныфны 3 укучы тәмамлады. Галиуллина Айсылу Казан шәһәренең Дизайн һәм технология көллиятендә товаровед белгечлеге үзләштерәчәк. Морадимов Илназ Түбән Кама шәһәренең Н.В.Лемаев исемендәге Нефтехимия көллиятендә аппаратчы-оператор белеме алачак. Шарифуллин Илсаф Казан шәһәрендә КНИТУ ның техник көллиятендә җитештерү сыйфаты белгечлеге өчен укуларын дәвам итәчәк.

IX сыйныфны 8 укучы тәмамлады. Шулардан Смолякова Анастасия КНИТУның Тимирясов исемендәге көллиятендә укуырга керде. Хәйруллин Данил Аксубай техникумында эретеп ябыштыручы һөнәрен алачак. Хәбибрахманов Ильяс Түбән Кама шәһәренең медицина көллиятендә укуын дәвам итә. Калган укучыларыбыз үзебезнең мәктәптә укуларын дәвам итәчәк.

***Илдар Хәбибуллин, укыту эшләре буенча директор урынбасары***


## Арча төбәгенә сәяхәт



Баланы үз милләтенең лаеклы вәкиле һәм камил шәхес буларак тәрбияләү өчен, аңа туган телен өйрәнү генә аз. Аның өчен тел милли гореф-гадәтләрне аңга сеңдерү, саклау, киләчәк буыннарга тапшыру чарасына әверелергә тиеш. Безнең мәктәп бу юнәлештә эшләүне ныклап, адымлап алып бара дисәм дә, ялгыш булмас. Әледән-әле милләтебезнең танылган шәхесләре белән очрашулар, милли бәйрәмнәр уздырылып килә.

Укучыларны тәрбияләүнең тагын бер уңышлы максаты – тарихи әһәмияткә ия урыннарга сәяхәтләр оештыру. Уку елы ахырына планлаштырган сәяхәтебезне Арча районына билгеләгән идек. Ни өчен дигәндә, беренчедән, агымдагы Туган телләр һәм халыклар бердәмлеге елында шагыйрьләре белән дан тоткан төбәктә булып кайтасы килде. Икенчедән, быел бөек шагыйребез Габдулла Тукайның 135 еллык юбилее туры килгәнгә, аның туган ягын күреп кайтуны максат иттек.

19 нчы июнь иртәсендә 8-11 нче сыйныф укучылары, Фәнүзә һәм Ләйсән апалар җитәкчелегендә, мәктәп автобусына утырып, ерак сәфәргә юл тоттык. Арчага барып җиткәч, биредәге истәлекле урыннары белән танышу Арча педагогия көллиятендә урнашкан, дөньяда бердәнбер булган “Әлифба” музееннан башланды. Монда без дөньядагы 300 дән артык халыкның әлифбалары күргәзмәсе, татар әлифбасы тарихы белән таныштык. Бу музейда 50 ел кулланылышта булган, һәрберебезгә хәреф таныткан Сәләй Вәгыйзов белән Рәмзия Вәлитова авторлыгында чыккан Әлифба тарихын тыңлау нык тәэсир итте. Әлифба музееннан соң Арчадагы “Казан арты” музеена киттек. Биредә халкыбызның тарихына кагылышлы бик күп экспонатлар күрдек.



Сәяхәтебезнең икенче өлеше Тукайның балачагы узган данлыклы Кырлай авылына бару иде. Кырлай безне үзенең милли мохиты, гүзәл табигате белән каршы алды. Бирредәге Тукай музеена кергәч, бәләкәй Апушның үзен күргән кебек хис иттек. Сәгъди абзый йорты безне узган гасырларга алып киткән кебек булды. Анда Апуш коесы, аның әкият геройларының сыннары бер могҗиза кебек иде. Сәяхәтебезнең кызыгы – музей артындагы Ия елгасы буасында көймәдә йөзү иде. Шул ук вакытта малайлар Тукай коенып үскән елгада шау-гөр килеп су керделәр.

Сәфәребез ахырында 9, 11 нче сыйныфларның чыгарылыш кичәсе уздырылды. Мәктәпне тәмамлаучы дусларыбыз Бөек Тукай һәйкәле янында, тантаналы рәвештә өлгергәнлек аттестатларын алдылар. Бу тантана күмәкләшеп “Туган тел” җырын башкару белән тәгәлләнде. Әлеге күркәм чара зур тормышка юл алучы иптәшләребез күңеленә милли горурлык өстәп, халкыбызның лаеклы шәхесләре булырга этәргеч бирер дип ышанасы килә.

Язмамның ахырында, сәяхәтебезне һәрвакыт оештыруга зур ярдәм иткән Арчы егете Фәрит җизнигә һәм көне буе безне йөрткән автобус шоферы Рифкать абыйга олы рәхмәтебезне җиткерәбез.

***Сара Насыйрова, XI сыйныф укучысы***

## Без тагын “Сәләттә”

Соңгы елларда җәйге каникуллар “Сәләт” лагеренда ял итү белән бәйле дисәк, ялгышмабыз. Быел да Биләрдәге “Сәләт” аланы безнең өчен истә калырлык итеп күңелле ял итү, дуслар табу өчен менә дигән урын булды. Биредә инде ничә елдан бирле күрешеп килгән дуслар җыела.

“Сәләт” – иң булдыклы, акыллы һәм талантлылар тупланган урын ул. Лагерьның төп максатларының берсе – балаларда ана телебезгә карата кызыксыну уяту, аралашу дәрәҗәсендә булса да татарча өйрәтү. Чөнки хәзерге чор татар балаларының шактые туган телләрен бик начар белә. Быел да биредә туган телне өйрәтү буенча мавыктыргыч дәресләр бирелде. Шулай ук төрле шәхесләр , журналистлар белән очрашулар оештырылды. Төрле аланнарда аерым юнәлешләр буенча эшләп, хәзерге заман һәм киләчәк һөнәрләрен үзләштерү мөмкинлекләре күрсәтелде. Быелгы белем бирү программасында робототехника, модельләштерү һәм дизайн юнәлешләре аерым урын алып торды. “Сәләттән” без җәйге ялның якты истәлекләре һәм яңа файдалы белемнәр белән кайттык.

***Зөлфирә Сафиуллина, X сыйныф укучысы***





## Яңа уку елына әзерлек

Һәркемгә билгеле булганча, җәй айлары мәктәпне яңа уку елына әзерләү дәвере булып тора. Узган җәй безнең мәктәптә бу юнәлештә шактый эш башкарылды. Иң беренче чиратта, замана афәтләреннән саклану максатыннан, балаларның һәм мәктәп хезмәткәрләренең иминлеген тәэмин итү чаралары күрелде. Укыту-тәрбия эшләре алып барыла торган һәр кабинетка һава чистарта торган рециркуляторлар куелды. Мәктәпнең эчен һәм тышкы тирәлеген тулысынча һәм даими күзәтеп тору мөмкинлеген бирерлек итеп видеокамералар урнаштырылды. Салкын айларда җитәрлек дәрәҗәдә җылынмаган бүлмәләргә җылылык радиаторлары өстәлде. Болардан тыш, ашханәгә үлчәү һәм яңа савыт-сабалар, территорияне яктырту өчен прожекторлар, мәктәпкә керүчеләрне тикшерә торган металл детекторлары алынды. Әлеге җиһазларны алу өчен, мәктәпнең бюджеттан тыш керемнәреннән, тулаем алганда, 254000 сум акча тотылды.

Туган телләр елы уңаеннан, татар телендә белем һәм тәрбия бирүче мәктәп буларак, Татарстанның мәгариф һәм фән министрлыгыннан Аксубай районына бирелгән ике интерактив тактаның берсе безгә тапшырылды. Шулай ук без республиканың татар мәктәпләре арасында уздырылган конкурста “Авыл мәктәбе – рухи мәдәният үзәге” дигән проект белән катнышып, **ярты миллион сумлык** грант отуга ирештек. Бу акчаларга мәктәпкә яңа буын компьютерлары, видеопроекторлар һәм башка кирәкле оргтехника алырга ниятлибез.

Житди житешсезлекләр булмау сәбәпле, быел мәктәптә зур ремонт эшләре башкарылмады. Белем бирү оешмаларының яңа уку елына әзерлеген тикшергән район комиссиясе безнең мәктәпне дәгъваларсыз кабул итте.

Шулай итеп, мәктәбебездә заман таләпләренә җавап бирерлек барлык шартлар да тудырылган. Аллага шөкер, матди яктан мөмкинлекләребез елдан-ел арта бара. Мәктәп хезмәткәрләренә намуслы итеп, җиренә җиткереп эшләргә, ә укучыларга тәртипле булып, тырышып укырга гына кала.

***Рафик Насыйров, мәктәп директоры***

## Мәктәптә җәйге лагерь



Мәктәптә уку елы тәмамлану белән укучылар ялга чыга. Балаларның җәйге ялын кызыклы һәм файдалы итеп уздыру максатыннан һәр ел саен июнь аенда мәктәп лагеры оештырыла.

Агымдагы елда лагерьга барлыгы 25 бала йөрде. Лагерьның һәр көне зарядка белән башланып китә. Аннан соң балалар иртәнге аш белән тамак ялгап алалар. Ашаганнан соң, һава торышына карап, төрле уеннар, мавыктыргыч чаралар үткәрелә. Тәрбияче Рузилә, Сирин һәм Олеся апалар балалар ялын көннән-көн кызыклырак, файдалырак үткәрергә тырышты. Ял итүчеләр ”Кояшкай” һәм “Туган авылым” төркемнәренә бүленеп эшләделәр. Һәр көн планлаштырган чара белән узды. Сәламәт яшәү рәвешенә чакырган "Начар гадәтләр зыянлы", "Яшеллек – яшәү чыганагы", "Күңелле зарядка", "Мажаралар иле" һ.б. шундый юнәлештәге уенлы чаралар үткәрелде. Мәдәният һәм сәнгать дөньясы да читтә калмаган: "Бөек Ватан сугышы башланган көн", "Авылым батырлары", "Үткәнне беләсеңме?", "Алло, без сәләтләрне эзлибез!" кебек кече бәйрәмнәр дә булып узды. Табигатьтә үскән бала нык һәм сәламәт булганны истә тотып, күп чаралар болында, су буйларында үткәрелде. Ял итүчеләр хәтта Чирмешән елгасына балык тотарга да бардылар.

Уеннар уен белән, тик тәмле ашамыйча, яллар кызык үтмәс иде. Пешекче Илсөяр апа ризыкларны тәмле дә, зәвыклы да итеп әзерләү серләрен бик яхшы белә. Ашханәдә көн саен бәйрәм рухы ясаган апаларына балалардан бары рәхмәт кенә ишетелде.

Ничек кенә мавыктыргыч булмасын, санаулы көннәр тиз үтә шул. 21 көн дәвамында күңелле итеп ял иткәннән соң, шат һәм канәгать балалар лагерь белән хушлаштылар.

***Виктория Нукина, X сыйныф укучысы***

## “Алтын каләм”гә бардым

Җәйге каникулларда ял гына түгел, кызыклы чаралар дәвере дә. Мин быелгы елның 23-27 июль көннәрендә «Идел» яшьләр үзәге базасында «Алтын каләм» — «Золотое перо» балалар, яшүсмерләр һәм яшьләр матбугатының XXVI Республика фестивалендә катнаштым. Фестивальне Татарстанның Яшьләр эшләре министрлыгы, «ТАТМЕДИА» агентлыгы, КФУ, Татарстан Журналистлар берлеге, «Татарстан — Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе оештырды. Чара билгеләнгән берничә юнәлештән мин фотожурналистиканы сайладым. Монда һәр юнәлешнең үз осталары укучыларга мастер-класслар үткәрде. Фотога төшерү серләрен өйрәтеп кенә калмадылар, төрле мавыктыргыч очрашулар да булды. Танылган язучылар, фотографлар, журналистлар безнең белән бергә эшләделәр.

***Самат Гафиятуллин, VIII сыйныф укучысы***